ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеге торышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеге торышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп торуны һәм хокук куллану тәҗрибәсен мониторинглауны дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының гарызнамәсенә бәйле рәвештә «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктының һәм 83 статьясындагы 9 өлешенең конституциячел булуын тикшерү хакындагы эш буенча» 2024 елның 26 сентябрендәге 41-П номерлы Россия Федерациясе Конституция Суды карары нигезендә федераль закон проектын эшләүдә катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. 2025 – 2030 елларда Татарстан Республикасы территориясендә «Дәвамлы һәм актив тормыш» һәм «Гаилә» яңа илкүләм проектларын, планлаштырылган максатчан күрсәткечләргә ирешеп, гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

4.2. «Дәвамлы һәм актив тормыш» яңа илкүләм проекты кысаларында билгеләнгән стратегик бурычларны үтәүне һәм халыкның үлемен киметүгә, яшәү, шул исәптән сәламәт яшәү, дәвамлылыгын арттыруга, сәламәт яшәү

рәвешен, алкоголь, тәмәке, никотинлы продукция куллануны киметүне дә кертеп, булдыруга юнәлдерелгән өстәмә чаралар күрүне тәэмин итәргә.

4.3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны реабилитацияләү, шул исәптән медицина реабилитацияләве, системасын камилләштерү эшен дәвам итәргә.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. «Гаилә» яңа илкүләм проектын гамәлгә ашыру максатларында ана һәм ата булуны саклау, балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтлеген, шул исәптән репродуктив сәламәтлекне, саклау чаралары комплексын күздә тотарга.

5.2. Хатын-кызлар консультацияләре челтәрен киңәйтүгә, перинаталь үзәкләрне, балалар поликлиникаларын һәм хастаханәләрен модернизацияләүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган балалар сәламәтлеген саклау объектлары инфраструктурасын модернизацияләү чараларын күрергә.

5.3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә расланган план нигезендә халыкны диспансеризацияләүне һәм профилактик медицина тикшерүен оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

5.4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә сәнәгать предприятиеләрендә Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары тарафыннан хезмәткәрләрне диспансеризацияләүне һәм профилактик медицина тикшерүен оештыру һәм үткәрү эшен дәвам итәргә.

5.5. Сирәк (орфан) авырулар белән интегүче затларны дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын күрергә.

5.6. Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларында кадрлар кытлыгын бетерү эшен активлаштырырга.

5.7. Көндәлек клиник практикага инновацион фәнни эшләнмәләрне гамәлгә кертүне дәвам итәргә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручы гражданнарның амбулатор гемодиализ үтү урынына баруын һәм яшәү урынына кире кайтуын оештыруда ярдәм күрсәтүне, әлеге категориядәге гражданнарны, җәмәгать транспорты булмаганда, гемодиализ үтү урынына алып баруда һәм алып кайтуда ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 161-VII ДС